# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**19 ноябрь 2021 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2 нче төркем инвалидлар өчен түләүне киметеп, 200 сум күләмендә калдырып, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Тымытык авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында янгын техникасын карап тоту (машина йөртүчеләрнең хезмәт хакын килешү буенча түләү, запчастьләр сатып алу);
- Тымытык авылында «Халыкара хатын-кызлар көне» «Җинү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», инвалидлар декадасы, «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авылында лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү;
- Тымытык авылында Пушкин ур., Полевая ур., буенча вак таш җәелгән юлларны профильләштерү (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авылы территориясен механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева